**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган муниципаль тур олимпиада биремнәре җаваплары**
**2025-2026 уку елы, 8 нче сыйныф**

**Максималь балл – 93**

**1. Озаглавьте картину. Составьте 5 вопросительных предложений по картине. (12 баллов, по 2 балла за каждый правильный ответ).**

**Ачкыч:** Китап яратучылар клубы. Бу картинада кемнәр сурәтләнгән? Укучылар нинди китаплар укыйлар? Укучылар кайда утыралар? Һ.б.

| 2 (1 балл) | 3 (1 балл) | 4 (1 балл) | 5 (1 балл) | 6 (5 балл) | 7 (1 балл) | 8 (4 балл) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| г | б | а | б | җитте<br>алып килде<br>капланды<br>башланды<br>күренде | в | 2 |

**9. Прочитайте текст, по содержанию текста в таблице ставьте “+” или “-”. (18 баллов)**

| № | Җөмләләр | Әйе | Юк |
|---|---|---|---|
| 1. | Декабрь - кышның беренче ае. | + | |
| 2. | Җир - ап-ак кар белән, агачлар көмеш бәс белән капланган. | + | |
| 3. | Һава чиста һәм салкын, һәр аваз еракка китеп тарала. | | + |
| 4. | Кояш югары күтәрелә. | | + |
| 5. | Кояшның аксыл яктысы кар өстендә зәңгәр күләгәләр ясый. | + | |
| 6. | Көндез тыныч, кар авырлыгы астында ботаклар сына. | | + |
| 7. | Кич бик соң җитә. | | + |
| 8. | Күк тиз караңгылана, йолдызлар кабына. | + | |
| 9. | Өйләрнең тәрәзәләрендә сары утлар җемелди. | | + |

**10. Допишите окончания слов в предложениях. (13 баллов)**

| № | **Предложения** | **Баллы** (макс.) 13) | **Сумма** (фактич.) ( ) |
|---|---|---|---|
| **1.** | Декабрь – ел**ның** соңгы ае, ул могҗизалар**га** бай. | 2 | |
| **3.** | Декабрь атама**сы** латинча decem («ун») сүзе**ннән** килеп чыга. | 2 | |
| **4.** | Борынгы грек календаре**нда** декабрь унынчы ай | 2 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | булган, чөнки ел март**тан** башланган. | | |
| **5.** | Шәһәр әкренләп бәйрәм**гә** әзерләнә: тәрәзәләр**дә** гирляндалар кабына, мәйданнар**да** чыршылар басып тора. | 3 | |
| **6.** | Һава**да** мандарин һәм ылыс исе аңкый. | 1 | |
| **7.** | Декабрь**дә** без һәр кар бөртег**ен** күреп калырга һәм үз йөрәгебез**гә** колак салырга тырышабыз. | 3 | |

**11. Используя содержание текста 9-го задания, составьте диалог из 10 реплик. (20 баллов, по 2 балла за каждую правильную реплику)**

**Ачкыч:**

- Дустым, декабрь нинди ай?
- Декабрь - елның соңгы ае.
- Декабрь сүзе нәрсәне аңлата?
- Аның исеме латин decem («ун») сүзеннән килеп чыккан.
- Декабрьдә һава торышы нинди?
- Җир ап-ак кар белән капланган. Һава чиста һәм салкын.
- Декабрьдә шәһәрләрдә яңа елга ничек әзерләнәләр?
- Тәрәзәләрдә гирляндалар кабына, мәйданнарда чыршылар басып тора, ә һавада мандарин һәм ылыс исе аңкый.
- Декабрьдә син нәрсә көтәсең?
- Мин могҗиза, яңа очрашулар көтәм.

**12. Напишите краткое сочинение-рассуждение о пользе чтения художественной литературы. (8 предложений - 16 баллов)**

**Ачкыч:**

Китап уку һәркемгә файдалы. Китап укыганда без геройларны, вакыйгаларны, табигать күренешләрен күз алдына китерәбез. Китаплар сүз байлыгын арттыра - без яңа сүзләрне истә калдырабыз, катлаулы җөмләләр төзергә өйрәнәбез. Әдәби әсәрләр кешеләрне яхшырак аңларга ярдәм итә. Моннан тыш, уку хәтерне һәм игътибарны арттыра. Китаплар белемнәрне киңәйтә: без төрле чорлар, мәдәниятләр һәм тарихи вакыйгалар турында беләбез. Уку - ял итү һәм стресстан чыгу өчен менә дигән мөмкинлек: кызыклы сюжет көндәлек тормыштан читкә китеп торырга ярдәм итә.